КАРАР

11.12.2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Югары Ослан авыл җирлегенең Киров исемендәге поселогы гражданнары
җыенының нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлегенең Киров исемендәге поселогында теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме? " - тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру, дигән сорау буенча 2024 елның 11 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә җыенның 246 катнашучысы, гражданнар җыенында катнашучы гражданнар саны - 84 кеше кертелгән. Кворум юк. Гражданнарның җыены көн тәртибенә кагылышлы карарлар кабул итәргә тиеш түгел.

Карар кабул ителде:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлегенең Киров исемендәге поселогы территориясендә гражданнар җыены үтмәгән дип санарга.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлегенең Киров исемендәге поселогы гражданнары җыенының нәтиҗәләрен Югары Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты
җитәкчесенең урынбасары Т.П.Белова